ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**13.01.2016**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 32**

Гаилә балалар бакчасы эшчәнлеген оештыру турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Мәктәпкәчә белем алу мөмкинлеген тәэмин итү һәм мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә йөрми торган балаларны һәрьяклап үстерү, мәктәпкәчә белем бирү системасының яңа формаларын үстерү, ана һәм балаларга ярдәм итү максатыннан, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:
1. 1.3.п.һәм 2.16. п. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 24 июлендәге 1679 номерлы карары белән расланган гаилә балалар бакчасы эшчәнлеген оештыру турындагы нигезләмәләрне түбәндәге редакциядә бәян итергә:

П. 1.3. «Гаилә балалар бакчалары 2 айдан 7 яшькә кадәрге өч һәм аннан күбрәк баласы булган күп балалы гаиләләрдә оештырыла. Әгәр күп балалы гаиләдә мәктәпкәчә яшьтәге бер яки ике бала булса, гаилә балалар бакчасын оештыру башка күп балалы гаиләләрдән мәктәпкәчә яшьтәге балаларны кабул иткән очракта рөхсәт ителә.

Муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренең структур бүлекчәләре рәвешендә төзелгән гаилә балалар бакчалары мәктәпкәчә белем бирү оешмалары, өстәмә белем бирү оешмалары базасында һәм башка җайлаштырылган биналарда, шул исәптән күп балалы гаиләнең яшәү урыны буенча, торак пункт чикләрендә урнашырга мөмкин».

П.2.16. "Балаларны тукландыруны оештырганда азык-төлек продуктларын саклау шартларына, аш-су һәм кулинария әйберләрен әзерләү һәм сату, меню төзүгә (төрле яшьтәге балаларны тукландыруны оештыру өчен), ризыкның кыска вакытлы кабул ителүенә, эчү режимын оештыруга карата чын санитар кагыйдәләр үтәлергә тиеш. Ашау ешлыгы балаларның тору вакыты һәм төркемнәрнең эш режимы белән билгеләнә (иртәнге яки төшке аш, яисә иртәнге һәм төшке аш, яисә төшлек, башка вариантлар булырга мөмкин). Балаларны

әзер ризыклардан һәм башка мәктәпкәчә оешмаларның азык-төлек, туклану бүлекләре яки җәмәгать туклануы база предприятиеләреннән изотермик савытта китерелә торган әзер кулинария продукциясеннән файдаланып туклandыруны тәэмин итү рөхсәт ителә.

Әзер беренче һәм икенче ашлар изотермик савытта (термосларда) вакыт дәвамында, температура тарату температурасыннан түбән булмаска, әмма 2 сәгатьтән дә артык булырга тиеш түгел. Әзер суынган кайнар ризыкларны җылытырга рөхсәт ителми. Әзер кулинария продукциясен һәм аш-суны күчерү рөхсәт ителми".

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы А. В. Старостин